

# «Бу тормышны бизәр өчен туганмын...”

## ЯКТАШЫБЫЗ ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИНЫҢ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ


НУРИМАНОВСКИЙ РАЙОН
Караидельский
район
Красная Горка
Казнаташ
Нур
Нов.Субай
Стар.Бияз
Рятуш
Новоисаево
Салдыбаш
Урман
район









Зиннур Сәгыйдулла улы Насыйбуллин 1937 елның 12 ноябрендә Нуриман районы Кече Теңкәш авылында колхозчы гаиләсендә туган.Ул кече яшьтән үк әдәбият белән кызыксына.Сукыр лампа яктысында мәктәп һәм авыл китапханәләренең барлык әдәби шигырьләрен мәктәп стена газеталарына урнаштырып сәхнәдән сөйләп иптәшләрен куандыра.



Яҡшы беләм: мин донъяға
Тормош өсөн тыуғанмын.
Тик белмәйем был тормошҡа
Ҡасан ғашиҡ булғанмын?
Был мөхәббәт әллә әсәй
Һөтө менән ингәнме,
Әллә уны ата-бабам
Мираҫ итеп биргәнме?
Белмәйем,ҡасан ғашиҡ
булғанмын.
Тик беләм: мин был тормошто
Биҙәр өсөн тыуғанмын.

З.Насибуллин

Согыштан соңгы еллардагы авырлыктар, гаиләдә хужалыкны алып барырлык кеше булмау сәбәпле, Зиннур 8 синыфтан соң колхозда төрле эшләрдә эшли, 1955-1958 елларда Ерак Көнчыгашта Хәрби Диңгез Флотында хезмәт итә.




Хәрби хезмәттән кайткач, Бәләбәй шәһәрендә киномеханик мәктәбен тәмамлап,1964 елның көзенә кадәр Нуриман районында тирә-як авылларда киномеханик булып эшли.







Ул бер үк вакытта, төп эшеннән аерылмыйча укып, өлгергәнлек аттестатына имтихан тота.Әдәбиятка,шигърияткә булган омтылышы аны Башкорт Дәүләт Унивеситетына филология факультетына алып килә.Ул 1964-1966 елларда БДУ укый.Бу елларда аның шигырьләре газета битләрендә һәм «Яшь көстәр» альманахында дөнья күрә.





1967 елның гыйнварыннан Зиннур Насыйбуллин университетның читтән тороп уку бүлегенә күчә һәм хезмәт юлын Башкортостанның район гәзитдәрендә әдәби хезмәткәр, аннары Уфада Башкортостан радиокомитетында мөхәррир булып эшли. 1969 елда ул Казан шәһәренә юл тота. 1969 елдан бирле З. Насыйбуллин — Казан радиокомитетында редактор хезмәтендә.





3. Насыйбуллинның матбугатта беренче шигырьләре башкорт балалар журналы «Пионер»да дөнья күрә, аннары бүтән газета-журналларда («Һәнәк», «Чаян»), «Яшь көстәр», «Беренче карлыгачлар» (1969) кебек күмәк җыентыкларда шигъри цикллары басыла.



Шагыйрьнең гражданлык, сугыш вакытына туры килгән авыр балачак һәм яшьлек мәхәббәте темаларына багышланган лирик шигырьләре «Тәлгәш» исемле җыентыгына тупланган.



# Поэтический конкурс имени Зиннура Насибуллина








Зиннур Насыйбуллин 1986 елның 8 январенда вафат булды.

Ул 1979 елдан. СССР Язучылар союзы члены иде.

## БИБЛИОГРАФИЯ

Тәлгәш: Шигырьләр.—Казан: Таткитнәшр., 1973.—136 б. 2000. Рец.: Гамбәров Н. Тәлгәшләрдә сусыл җимешләр.— Казан утла» ры, 1973, № 10, 181—183 б.; Рәшитов Ә. Шигъри тәлгәш.—Татарстан яшьләре, 1973, 26 июль; Хөсни Ф. Шулардай берсе.—Соң Татарстан, 1973, 22 июль.

## Аның турында

Хөсни Ф. Зиннур Насыйбуллин.—Казан утлары, 1980, № 8, 170 б.